КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 19 июль г.Казань № 509

Спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлеге дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын күтәрү, халыкның барлык категорияләре өчен аны алырлык булуын тәэмин итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче оешмаларга таләпләрне стандартлаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлеге дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын расларга.
2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына әлеге карар белән расланган Стандартны муниципаль учреждениеләр күрсәтә торган тиешле муниципаль хезмәтләр сыйфатын бәяләү өчен тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның көче 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин